| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ КАРАДУВАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КАРАДУГАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«30» сентябрь 2024 ел № 102

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Карадуган авыл җирлеге Советының 29.06.2022 ел, №49 «Мөлкәткә салым турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, «Татарстан Республикасы территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым буенча салым базасын салым салу объектларының кадастр бәясеннән чыгып, билгеләү тәртибен куллана башлауның бердәм датасын билгеләү турында» 2014 елның 30 октябрендәге 82-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Карадуган авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Карадуган авыл җирлеге Советының «Мөлкәткә салым турында» 29.06.2022 ел, №49 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

1.1. 2.4 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2% әлеге Кодексның 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектларына карата (гомуми мәйданы 1000 квадрат метрдан артыграк булган административ-эшлекле үзәкләрдән һәм сәүдә үзәкләреннән (комплексларыннан) һәм алардагы урыннардан тыш), әлеге кодексның 378.2 статьясындагы 10 пунктындагы икенче абзацында каралган салым салу объектларына карата, шулай ук һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектларына карата;

1.2. 2.6 пунктчасы өстәргә. түбәндәге эчтәлекле:

«2025-2027 еллар чорына 1,2% гомуми мәйданы 1000 квадрат метрдан артыграк булган административ-эшлекле үзәкләргә һәм сәүдә үзәкләренә (комплексларына) һәм алардагы Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән урыннарга карата»;

1.3. 2.6 пунктчаны 3 пункт дип санарга, 3 пунктны 4 пункт дип санарга, 4 пунктны 5 пункт дип санарга, 5 пунктны 6 пункт дип санарга, 6 пунктны 7 пункт дип санарга.

2.Әлеге карарның гамәлдә булуы 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карар Татарстан Республикасының (http:pravo.tatarstan.ru) рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм Балтач муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында рәсми басылып чыккан көненнән кимендә бер ай узгач үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Карадуган авыл җирлеге башлыгы: Ш.В.Низамиев